ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КӨШКӘТ
КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«14» апрель 2025 ел

**КАРАР**
№ 22

**Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтарырга тыелган урыннарны билгеләү һәм хуҗасыз хайваннарны аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге хакында**

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 6.1 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022 елның 8 нче ноябрдагы №51 карары белән кабул ителгән «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясы нигезендә, Урта Көшкәт авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Билгеләргә:

1) Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны (1 нче кушымта);

2) Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге (2 нче кушымта).

2. Хуҗасыз хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар формасын раслarga (3 нче кушымта).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Урта Көшкәт авыл җирлегенең рәсми сайтында (www/baltasi.tatarstan.ru) урнаштырылган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Ю.М.Перфилов

Урта Көшкәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
14.04.2025 №22 карарына
1 нче кушымта

Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә
хуҗасыз хайваннарны кайтару тыелган урыннар

1) парклар территорияләре;
2) балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары;
3) актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;
4) зиратлар һәм мемориаль зоналар;
5) массакүләм чаралар уздыру өчен мәйданчыклар;
6) балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре;
7) мәдәният объектларына якын территорияләр;
8) җәмәгать туклануы оешмаларына якын территорияләр;
9) сәүдә-күңел ачу үзәкләре территорияләре;
10) кибетләр территорияләре;
11) йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар;
12) тимер юл һәм автомобиль вокзаллары (станцияләре), диңгез һәм елга портлары, аэропортлар (аэродромнар)территорияләре;
13) көнкүреш калдыкларын урнаштыру объектларына якын территорияләр;
14) көнкүреш калдыкларын туплау урыннары чикләрендәге территорияләр;;
15) җылылык челтәрләре чикләрендәге территорияләр;
16) һәйкәлләргә якын территорияләр;
17) автобус тукталышлары янында.

Урта Көшкәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
14.04.2025 №22 карарына
2 нче кушымта

Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә
хуҗасыз хайваннарны аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында
карарлар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы

Урта Көшкәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
14.04.2025 №22 карарына
3 нче кушымта

Форма

# РЕШЕНИЕ О ВОЗВРАТЕ ЖИВОТНЫХ БЕЗ ВЛАДЕЛЬЦЕВ НА ПРЕЖНИЕ МЕСТА ОБИТАНИЯ

от «____» __________ 20__г. № ______

______________________________________________________________________

(Ф.И.О., должность лица, уполномоченного на принятие решения о возврате животных без владельцев)

на основании представленного ________________________________________

(полное наименование специализированной организации по отлову)

акта проведения освидетельствования животного без владельца на предмет наличия (отсутствия) у него немотивированной агрессивности, проведенного комиссионно с обязательным участием специалиста в области ветеринарии от «___» _______ 20___г. № ____

в отношении животного без владельца:

идентификационная метка ___________________________________________

место и дата отлова ________________________________________________,

ПРИНЯТО РЕШЕНИЕ:

______________________________________________________________________

(о возврате животного без владельцев на прежнее место обитания/запрете возврата)

______________________________________________________________________

(указывается основание принятого решения)

________________________ ______________________________________________

(подпись) (Ф.И.О.)